# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О дополнительных ограничениях времени, условий и мест розничной продажи алкогольной продукции на территории Республики Татарстан и признании утратившими силу некоторых законодательных актов Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 февраля 2015 года

**Статья 1**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 22 ноября 1995 года № 171-ФЗ «О государственном регулировании производства и оборота этилового спирта, алкогольной и спиртосодержащей продукции и об ограничении потребления (распития) алкогольной продукции» устанавливает дополнительные ограничения времени, условий и мест розничной продажи алкогольной продукции на территории Республики Татарстан в целях защиты нравственности, здоровья, прав и законных интересов граждан.

**Статья 2**

На территории Республики Татарстан не допускается розничная продажа алкогольной продукции (включая пиво и пивные напитки, сидр, пуаре, медовуху):

1) с 22 часов до 10 часов, за исключением розничной продажи алкогольной продукции при оказании услуг общественного питания на предприятиях общественного питания, отнесенных к типам «ресторан», «кафе», «бар» в соответствии с национальным стандартом Российской Федерации ГОСТ Р 50762-2007 «Услуги общественного питания. Классификация предприятий общественного питания», а также розничной продажи алкогольной продукции магазинами беспошлинной торговли;

2) на предприятиях общественного питания, размещенных в нестационарных объектах;

3) на предприятиях общественного питания, расположенных в многоквартирных домах, а также в пристроенных, встроенных, встроенно-пристроенных помещениях к многоквартирным домам, за исключением предприятий общественного питания, отнесенных к типам «ресторан», «кафе»;

4) с 22 часов до 10 часов на предприятиях общественного питания в закрытой таре (на вынос);

5) на предприятиях общественного питания, отнесенных к типам «ресторан», «кафе», и предприятиях торговли, расположенных в многоквартирных домах, вход для покупателей (потребителей) в которые организован со стороны двора (дворов) многоквартирного дома.

**Статья 3**

Ограничения, установленные пунктами 2, 3 и 5 статьи 2 настоящего Закона, применяются в отношении организаций, осуществляющих на день вступления в силу настоящего Закона розничную продажу алкогольной продукции, и индивидуальных предпринимателей, осуществляющих на день вступления в силу настоящего Закона розничную продажу пива и пивных напитков, сидра, пуаре, медовухи, при оказании ими услуг общественного питания по истечении трех месяцев после дня вступления в силу настоящего Закона.

**Статья 4**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 22 ноября 2010 года № 80-ЗРТ «Об установлении ограничения времени розничной продажи алкогольной продукции на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 11);

2) Закон Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 69-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об установлении ограничения времени розничной продажи алкогольной продукции с содержанием этилового спирта более 15 процентов объема готовой продукции на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10);

3) Закон Республики Татарстан от 20 мая 2013 года № 40-ЗРТ «О внесении изменения в статью 2 Закона Республики Татарстан «Об установлении ограничения времени розничной продажи алкогольной продукции на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 5).

**Статья 5**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
6 марта 2015 года
№ 10-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Закон гражданнарның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында “Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында” 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр билгели.

**2 статья**

Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен (сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны кертеп) ваклап сату рөхсәт ителми:

1) 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр, “Җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү. Җәмәгать туклануы предприятиеләре классификациясе” ГОСТ 50762-2007 Россия Федерациясе илкүләм стандарты нигезендә “ресторан”, “кафе”, “бар” типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләрендә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтелгәндә алкоголь продукциясен ваклап сатудан, шулай ук пошлинасыз сату кибетләрендә алкоголь продукциясен ваклап сатудан тыш;

2) стационар булмаган объектларда урнашкан җәмәгать туклануы предприятиеләрендә;

3) күпфатирлы йортларда, шулай ук күпфатирлы йортларга өстәп төзелгән, кушып төзелгән, кушып-өстәп төзелгән биналарда урнашкан җәмәгать туклануы предприятиеләрендә, “ресторан”, “кафе” типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләреннән тыш;

4) 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр җәмәгать туклануы предприятиеләрендә ябык савытта (алып чыгу өчен);

5) сатып алучылар (куллланучылар) өчен керү урыны күпфатирлы йортның ишегалдыннан (ишегалларыннан) оештырылган "ресторан", "кафе" типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләрендә һәм күпфатирлы йортларда урнашкан сәүдә предприятиеләрендә.

**3 статья**

Әлеге Законның 2 статьясындагы 2, 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм әлеге Закон үз көченә кергән көнгә сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатуны гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарларга карата әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай узгач кулланыла.

**4 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11);

2) "Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2011 елның 10 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10);

3) "Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2013 елның 20 маендагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 5).

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 6 марты
№ 10-ТРЗ